| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«12» февраля 2024г. № 25

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 17 мартындагы 50 номерлы «Теләче муниципаль районы «Район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан керем китерә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турында нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы нигезендә, Теләче муниципаль районының Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 17 мартындагы 50 номерлы «Теләче муниципаль районы «Район Мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан керем китерә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турында нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган Теләче муниципаль районының «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында нигезләмәнең 7.5 пунктындагы 9 абзацында «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 1992 елның 05 маендагы 431 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы» сүзләрен «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин